| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |

« 8 » ноября 2019 с. Тюлячи № 631

Гайләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче милкендәге 2019 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

"Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү Методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 декабрендәге 821/пр номерлы «Россия Федерациясе буенча 2019 елның беренче яртыеллыгына торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе турында» боерыгы, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә, Теләче муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарны 2019 елга аз керемле дип таный торган карарны кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә салым салына торган ялгыз яшәүче гражданинның милек бәясенең чик күрсәткече:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен – 848248,5 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 1079589 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 1388043 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 1850724 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 42313405 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 2776086 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 3238767 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 3701448 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме, хисап (1 нче кушымта) нигезендә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен – 18686,9 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен –11891,66 сум;

1.2.3. Өч яисә күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 10192,85 сум.

2. Җирле үзидарә органнарына, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Теләче муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтына куеп халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Х. Хәмидуллинга йөкләргә.

Җитәкчесе Н.Н. Хаҗипов

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.11 2019 ел №631 номерлы
карарына кушымта

# МЕТОДИКА

гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче милкендәге һәм 2019 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү буенча

1. Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яисә мөлкәт бәясенең кимчелеге;
НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны;
РЦ - РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясе (2019 елның өченче кварталына - 25705 сум).

а) ялгыз яшәүче гражданин өчен
СЖ = 25705 х 33 = 848248,5 сум
б) ике кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 25705 х 42 = 1079589 сум
в) өч кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 25705 х 18 х 3 = 1388043 сум
г) дүрт кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 25705 х 18 х 4 = 1850724 сум
д) биш кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 25705х 18 х 5 = 2313405 сум
е) алты кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 25705х 18 х 6 = 2776086 сум
ж) җиде кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 25705х 18 х 7 = 3238767 сум
3) сигез кешедән торган гаилә өчен:
СЖ = 25705 х 18 х 8 = 3701448 сум

2. Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең чик күрсәткече:

$$ПД = 0,7 \times СЖ \times ПС / (1 - (1 + ПС)^{-КП}) / (0,3 \times РС)$$

ПД - СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма); (Россия Федерациясе Үзәк банкы ставкасы елына 7,75 %, ягъни аена 7,75/100/12=0,0065).

КП - кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

Торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе Татарстан Республикасы буенча «2019 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе турында» 2018 елның 19 декабрендәге 822/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы нигезендә 25 мең 705 сум күләмендә билгеләнгән.

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткече исәп-хисабы

№ 1 таблица

| НП – торак бина нормасы (кв.м) | СЖ – торак бина алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС – гаилә әгъзалары саны (чел.) | РЦ – 1 кв.м. торак бинаның базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча бер айга процент ставкасы, % | КП – кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатыйр бәясе нисбәте | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык керем белән нисбәте | ПД- Керемнең чик күрсәткече (сум) (бер кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | 25705 | 7,75/100/12= 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 33 | 848248,50 | 1 | 25705 | 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | 18686,90 |
| 42 | 1079589,00 | 2 | 25705 | 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | 11891,66 |
| 54 | 1388043,00 | 3 | 25705 | 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | 10192,85 |
| 72 | 1850724,00 | 4 | 25705 | 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | 10192,85 |
| 90 | 2313405,00 | 5 | 25705 | 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | 10192,85 |
| 108 | 2776086,00 | 6 | 25705 | 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | 10192,85 |
| 126 | 3238767,00 | 7 | 25705 | 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | 10192,85 |
| 144 | 3701448,00 | 8 | 25705 | 0,0065 | 180 | 0,7 | 0,3 | 10192,85 |